**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

09.12.2019 1346-п

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектлары: Чупай, Ерсубай, Кондыз, Казакъ, Оштырма, Лубян, Бурец (Бура), Мәләкәс, Шукралинка (Чаллы), Бәтке, Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлегендәге исемсез күлләрнең су саклау зоналарын һәм яр буе яклагыч полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Су кодексының 26, 65 статьялары, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында»гы федераль законның 32 статьясының 1, 3 – 13, 15, 15(1) өлешләре нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт кадастр исәбен алып баруга, хокукларны дәүләт теркәвенә алуга, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруга һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне тапшыруга вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына (аның территориаль органнарына) җибәрелә яки тапшырыла торган документларны тапшыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1532 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлектә су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары, Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан федераль мөлкәттәге һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен саклау чараларын гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтен гамәлгә ашыру буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2010 елның 29 сентябрендәге 425 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектлары: Чупай, Ерсубай, Кондыз, Казакъ, Оштырма, Лубян, Бурец (Бура),

Мәләкәс, Шукралинка (Чаллы), Бәтке, Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлегендәге исемсез күлләрнең яр линияләрен (су объекты чикләрен), су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү турында» 2019 елның 19 мартындагы 1-Ф/2019 номерлы дәүләт контракты кысаларында башкарылган эш йомгаклары буенча Максатчан фараз күрсәткечләренә ирешүгә юнәлдерелгән һәм 2019 елда су мөнәсәбәтләре өлкәсендәге Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акча хисабыннан финанслана торган чаралар исемлеге нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналарының һәм яр буе саклык полосаларының урнашкан урынын һәм киңлеген Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып билгеләргә:

1.1. Чупай елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м; ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.2. Ерсубай елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м; ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.3. Кондыз елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м; ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.4. Казакъ елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.5. Оштырма елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м; ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.6. Лубян елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м; ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.7. Бурец (Бура) елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 200 м.

1.8. Мәләкәс елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м; ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.9. Шукралинка (Чаллы) елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 200 м.

1.10. Бәтке елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 200 м.

1.11. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә 16:39:101001:611 кадастр номеры беркетелгән җир кишәрлеге территориясендәге исемсез күл:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м; ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.12. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә 16:39:103601:268 кадастр номеры беркетелгән җир кишәрлеге территориясендәге исемсез күл:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м; ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (О.Г. Германова) материалларны билгеләнгән тәртиптә дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурсларының федераль агентлыгына җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Л.Н.Мөлекова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (М.М. Шәехов) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Шиһаповка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков